| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**Приказ** **Боерык**

20.12.2017 г. Казань № 204-од

Җирле әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территорияләрне оештыру турындагы карарны яраштыру Тәртибен раслау турында

1995 елның 14 мартыннан 33-ФЗ номерлы "Аерым саклана торган табигый территорияләр турында"гы Федераль канунның 2 маддәсендәге 8 пунктын һәм Татарстан Республикасы Экологик кодексының 142 маддәсен тормышка ашыру максаты белән **боерам:**

1. Кушылып бирелгән җирле әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территорияләрне оештыру турындагы карарны яраштыру Тәртибен расларга.

2. Бу боерыкның үтәлүен тикшерүне Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Ю.Б. Матвеевка тапшырырга.

Рәис Ф.С.Батков

Татарстан Республикасының
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының
_______ 2017 елдан
_____ номерлы боерыгы
белән расланган

**Җирле әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территорияләрне оештыру турындагы карарны яраштыру Тәртибе**

1. Бу Тәртип, муниципаль оешманың милегендә булган, җир бүлемтекләреннән гомуми мәйданның 5 проценттан күбрәген алып, җирле әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территорияне (алга таба -АСТТ) оештыру турында җирле үзидарә әгъзасының карарын яраштыру процедурасын урнаштыра.( алга таба – Тәртип)

2. Җирле әһәмияттәге АСТТ оештыру турында карар, җирле әһәмияттәге АСТТ оештырыла торган территориядәге җирле үзидарә әгъзалары белән кабул ителә. Андый карарны кабул иткәннән соң Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына (алга таба – Вәкаләтле әгъза) документларны кушып үтенеч язуы (бу Тәртипнең 1нче кушымтасы) җибәрелә.

3. Бу тәртипнең 1 нче кушымтасында күрсәтелгән мәгълүматлар яки документлар булмаган очракта, Вәкаләтле әгъза, аны алган көннән, эш көнендә санала торган, 3 көн эчендә үтенеч язуын кайтара.

4. Утенеч язуы бу Тәртипнең таләпләренә туры килгән очракта, Вәкаләтле әгъза үтенеч язуын алган көннән, эш көнендә санала торган 5 көн эчендә, аның күчермәсен Татарстан Республикасының бердәм идарәара электрон документ әйләнеш системасы аша, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгына, аның компетенциясенә кагылышлы сорауларны карау өчен җибәрә.

5. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы билгеләнгән тәртиптә, яңа оештырыла торган җирле әһәмияттәге АСТТ оештыру максатларына һәм мәсьәләләренә туры килүе турындагы нәтиҗәне юнәлтә. ( алга таба –нәтиҗә)

6. Вәкаләтле әгъза, бу Тәртипнең 5нче пункты белән каралган, нәтиҗәне алган көннән, эш көнендә санала торган ун көн эчендә:

җирле әһәмияттәге АСТТ оештыру турында карарны яраштыра;

кире кагу өчен нигезләрне күрсәтеп, яраштырудан баш тарта.

7. Кире кагу өчен нигезләр:

теркәлгән документларда ышанычсыз мәгълүматлар булу;

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының тискәре нәтиҗәсе.

8.Җирле үзидарә әгъзасы, кире кагу сәбәпләрен бетергәннән соң, Вәкаләтле әгъзага үтенеч язуын кабат бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасының
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының

_______ елдан _____номерлы
боерыгы белән расланган
җирле әһәмияттәге аерым
саклана торган табигый
территорияләрне оештыру
турындагы карарны яраштыру
Тәртибенә 1нче кушымта

Татарстан Республикасының Биологик
ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә

**Үтенеч язуы**

_______________________________________________________________

(муниципаль районның җирле үзидарә әгъзасы)

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетыннан

"____________________________________________________________"

(исеме)

__________________________________________________категориясендә

мәйданы ___________________ (га) _______________ чикләрендә урнашкан

_______________________________________________________________

(координат нокталарын күрсәтеп чикләргә тасвирлама)

җирле әһәмияттәге аерым саклана торган табигый территорияне оештыру турындагы карарны яраштырырга сорый.

Кушымталар:

1. Җирле әһәмияттәге АСТТ оештыру турында кагыйдәләр проекты;
2. Оештырыла торган җирле әһәмияттәге АСТТ чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләренең хосусый милек ияләре, хуҗалары һәм кулланучылар белән яраштырулар;
3. Территориянең( акваториянең) табигатен саклау, экологик- танып белү һәм ял иттертүнең аерым кыйммәтенә фәнни нигезләү, җирләрнең экспликациясе һәм җирле әһәмияттәге АСТТга тискәре йогынтылар ( факторлар, хәвеф хәтәрләр).

Муниципаль оешма башлыгы ______________________________